**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карары**

Чубар-Абдул авылы № 176 19 май 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Чубар-Абдул_ авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Кушымта итеп бирелгән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектын 2013 елның 7 октябере 78 номерлы карары 18.03.2014 №98, 16.08..2014 №116, 25.08.2017 №65, 06.03..2019 №130) карарлар редакциясендә) хупларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул_ авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 2013 елның 7 октябере 78 номерлы карары 18.03.2014 №98, 16.08..2014 №116, 25.08.2017 №65, 06.03..2019 №130) белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

3. Билгеләргә:

- уздыру вакыты – 2020 елның 28 маеннан 2020 елның 30 июненә кадәр;
- үткәрү урыны – Чубар-Абдул авылы, Совет урамы, 85 йорт;
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2020 елның 30 июненә кадәр - Чубар-Абдулавылы, Совет урамы, 85 йорт, Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетына (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр төшке ашка 12.00 сәгатьтән 13.00

сәгатькә кадәр тәнәфес) кертелә ала.

4. Халык тыңлаулары үткәрү буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

- Фәтхетдинов Н.Ә.– Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы;
- Рафиков Г.Г. –Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының № 1округ депутаты;
- Шафигуллин Р.Г. – авыл җирлеге Советының № 7_округ депутаты;

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул_ авыл җирлеге Советының 2013 елның 7 октябере 78 номерлы карары 18.03.2014 №98, 16.08..2014 №116, 25.08.2017 №65, 06.03..2019 №130) белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча эшче группага ачык тыңлаулар уздыруны, гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссия, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә.

7. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән, 2020 елның 25 маеннан да соңга калмыйча халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н.Ә. Фәтхетдинов

ЧУБАР АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ЧУБАР-АБДУЛЛОВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Чубар-Абдул_ авыл Советының
2020 елның 19 маендагы 176
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул__авыл җирлеге Советы карары**

Чубар-Абдулавылы №___ Чубар-Абдул 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул_авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2013 елның 7 октябрь 78 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (18.03.2014 №98, 16.08..2014 №116, 25.08.2017 №65, 06.03..2019 №130 номерлы карарлар редакциясендә)

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «_____ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Чубар-Абдул_авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул_авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2013 елның 7 октябрь 78 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (18.03.2014 №98, 16.08..2014 №116, 25.08.2017 №65, 06.03..2019 №130 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2. пунктның өченче абзацында «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1.3. пунктның унынчы абзацында «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен

«каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 2.7. пунктта «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 2.10.3 – 2.11.2, 2.11.4 пунктларда «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә, «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.5. Түбәндәге эчтәлекле 2.11.7 пункт белән тулыландырырга:

«2.11.7. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н.Ә. Фәтхетдинов